*Грамматическое обучение осуществляется методом аналитико-синтетического звука-буквы, заключающегося в начальном процессе обучения грамоте, тесно связанном чтении и написании; подкрепляется навыками работы над звуками и буквами, слогами и словами, предложениями и связной речью. В то же время интерес к книгам, изданным для малышей, создается самостоятельно. Со временем можно познакомить и с изданными для детей журналами - в этой работе основным методом является привычка слушать внеклассное чтение, рассказывать о содержании произведения в зависимости от рисунков, читать названия книг, журналов, произведений;*

Грамотага өйрәтү үзара тыгыз бәйләнгән укый һәм яза белергә өйрәтүнең башлангыч процессыннан гыйбарәт аналитик-синтетик аваз-хәреф методы белән тормышка ашырыла; авазлар Һәм хәрефләр, иҗекләр һәм сүзләр, җөмләләр һәм бәйләнешле сөйләм өстендә эшләү күнегүләре аша ныгытыла. Шул ук вакытта нәниләр өчен басылган китаплар белән кызыксыну да уятыла, мөстәкыйль укырга омтылыш тудырыла. Тора-бара кечкенәләр өчен чыгарылган журналлар белән дә таныштырырга мөмкин- Бу эштә укытучы дәрестән тышукыганны тыңларга гадәтләндерү, рәсемнәргә карап, әсәрэчтәлеген сөйләп күрсәтү, китап, журнал, әсәр исемнәрен уку кебек гамәлләр төп ысул булып тора.

*Звук, буквенно-опознавательная единица, изъявительная единица, словообразовательная единица, предложение — информационно — коммуникативная единица (птица летает). Плавает рыба."Истинное чтение и истинное письмо", начатое с чтения предложения и написания предложения.*

Аваз,хәреф — тану берәмлеге, иҗек — уку берәмлеге, сүз —аңлау берәмлеге, җөмлә — мәгълүмат-хәбәрлек берәмлеге (*Кош оча. Балык йөзә.)* икәнен гамәли аңлап, «чын уку һәмчын язу»ның җөмлә укудан һәм җөмлә язудан башланганын белеп эшләүләренә ирешелә.

**Подготовительный период**

**Әзерлек чоры**

***Речь.*** *Общее представление о том, что люди говорят и пишут. Умение красиво говорить, читать и писать.*

**Сөйләм.** Кешеләрнең әйтеп Һәм язып сөйләшүләрен гомуми күзаллау. Матур итеп сөйләшә, укый һәм яза белү кирәклеген аңлау.

***Предложение и слово.*** *С помощью графических схем можно разделить речь на предложения, предложения, разобрать слова на предложения и звуки.*

**Җөмлә һәм сүз.** График схемалар ярдәмендә сөйләмне —җөмләләргә, җөмләне сүзләргә аеру, сүзләрне иҗек һәм авазларга таркату.

***Слоги.*** *Слова, начинающиеся с гласных и согласных ((уң, ил, ант), слогов, начинающиеся с согласных и согласных звуков (чабу, күл-мәк, сирт-мә, шо-мырт). Ударение на словарные звуки (у-мар-таа) или ударение на слова (әә-реек-мәән), разбор слова на слоги и определение количества слогов в слове на согласные звуки.*

**Иҗекләр.** Сузык аваздан торган һәм сузык аваздан башланган иҗекләр *(уң, ил, ант),* кушылмадан торган һәмкушылма авазлардан башланган иҗекләр *(чабу, күл-мәк, сирт-мә, шо-мырт).* Сузык авазларга басым ясап *(у-мар-таа)* якисуза төшеп *(әә-реек-мәән),* сүзләрне иҗекләргә бүлеп әйтү һәм сүздәге иҗекләр санын сузык авазларга карап билгеләү.

***Звуки и буквы.*** *Создать представление о звуке. Произнося и слыша звонкие и глухие звуки, глухие и глухие. т. е. уметь различать задержку или задержку дыхания (т — а) во рту в зависимости от произношения (а — а), звучания или шепота (з - с). Литературно правильное произношение звуков.*

**Авазлар һәм хәрефләр**. Аваз турында күзаллау тудыру. Сузык һәм тартык авазларны, калын һәм нечкә сузыкларны, яңгырау һәм саңгырау тартык авазларны әйтеп һәм ишетеп. ягъни конкрет  авазны әйткәндә авыз эчендә сулышның тоткарлануы яки тоткарланмавына *(т — а),* калын яки нечкә әйтелүенә *(а — ә),* яңгырап яки пышылдап ишетелүенә *(з - с)* карап аера белү. Авазларны әдәби дөрес әйтү.

*Разбор отдельных слов (слов или кавычек)-это разбор слов по схеме-моделям, показывающий количество звуков в словах, их характерные признаки, порядок в слове и показывающий строение слышимого слова в их изъявительном наклонении, т. е. умение видеть изложения и звуки конкретного слова в схеме в словесном порядке.*

Аерым (сузык яки тартык) авазны сүздән аерып алу сүзләргә иҗек-аваз анализы ясау (сүзләрдәге авазлар санын, аларның характерлы билгеләрен, сүздәге тәртибен күрсәтә әйтелгән һәм ишетелгән сүзләрне аларның иҗек-аваз төзелешен күрсәткән схема-модельләр белән бәйләү, ягъни конкрет сүзнең иҗек һәм авазларын сүздәге тәртиптә схемада күрә белү.

*Самостоятельно придумать слова, предложенные учителем (ш: камень, шар, бутылка)...); поиск готовых звуковых схем слов.*

Укытучы тәкъдим иткән аваз кергән сүзләрне мөстәкый уйлап табу *(ш: таш, шар, шешә...);* сүзләрнең әзер иҗек-аваз схемаларын эзләп табу.

### Период алфавита или основной период
### Әлифба чоры, яки төп чор
### Обучение чтению

*Знакомство со словарными гласными и согласными звуками и их буквами, определяющими произношение слов: твердый и мягкий. Наблюдение за произношением слов в зависимости от букв словарного запаса (урыла — үрелә).*

*Чтение и составленных из изученных букв слогов, слов  и словосочетаний.*

*Сначала разберем по звуку и сделаем дальнейший анализ, произнесем в уме, составим слова из срезанных букв и срезанных сочетаний (та, ла, тә, ти) и чтение построенные слов вслух.*

*Чтение букв в прямом и относительно быстром ключе, в смысле звуков в живом слове (крупный — [эрэ], тиен -[тийэн], Юка — [Юка], юка — [Юка] и др.). Чтение слов, начинающихся со слов (ал, ит, огонь), двух согласных (а/л, та/ти, а/ти), состоящих из слов и сочетаний; затем чтение слов, образованных из слогов, начинающихся с приставок по артикуляционным единицам (ма, ма:к:п; к:р:т:к, ба:л:р:н); в конце прямое изложение слов и прочтение кратких и простых слов в целом. Последовательная тренировка грамотно и плавно читать слова, короткие простые предложения, маленькие, понятные детям тексты.*

*Изучение на примере учителя, уделяя внимание интонациям и паузам, соответствующим конечным звуковым признакам простого предложения (точка, вопрос, призыв), равнозначным частям предложения, родственным словам.*

*Познакомить детей с правилами учебной гигиены, воспитывать привычку к постоянному соблюдению правил.*

**Укырга өйрәтү**

Сузык һәм тартык авазлар һәм аларның хәрефләре белән сүзләрнең калын һәм нечкә әйтелешен билгеләүче калын һәм нечкә сузык авазлар белән танышу. Сузык аваз хәрефләренә карап, сүзләрнең калын һәм нечкә әйтеп укылуын күзәтү *(урыла — үрелә)*.

Сузык аваз хәрефләренә карап, кушылмадан торган (ике хәрефле ачык) иҗекләрне, өйрәнелгән хәрефләрдән төзелгән иҗекләрне телдән аваз анализы һәм синтезы ясалганнан соң уку.

Башта — аваз анализы ясап, алга таба анализ ясамый гына күңелдән әйтеп, кисмә хәрефләрдән һәм кисмә кушылмалардан *(та, ла, тә, ти)* сүзләр төзү һәм төзелгән сүзләрне кычкырып уку.

Хәрефләрне дөрес һәм чагыштырмача тиз танып, җанлы сүздәге авазлар мәгънәсендә уку *(эре — [эрэ], тиен -[тийэн], юкә — [йүкә], юка — [йукъа]* һ. б.). Сузыктан башланган ике хәрефле *(ал, ит, үт),* сузыктан һәм кушылмалардан торган ике иҗекле *(а/ла, тә/ти, ә/ти)* сүзләрне уку; аннары артикуляцион берәмлекләр буенча кушылмалардан башланган иҗекләрдән төзелгән сүзләрне уку *(мә, мә:к т.ә:п; кө:р:т ле:к, ба:л ты:р га:н);* ахырдан сүзләрне турыдан-туры иҗекләп, кыска һәм гади сүзләрне бөтен килеш әйтеп уку. Сүзләрне, кыска гади җөмләләрне, балаларга аңлаешлы кечкенә текстларны аңлап, әдәби дөрес һәм салмак итеп, сүзләп кычкырып укырга эзлекле күнектерү.

Гади җөмлә ахырындагы тыныш билгеләренә (нокта, сорау, өндәү), җөмлә эчендәге тиңдәш кисәкләргә, эндәш сүзләргә туры килгән интонация һәм паузаларга игътибар итеп, укытучы үрнәгендә укырга өйрәнү.

Уку гигиенасы кагыйдәләре белән балаларны таныштыру, кагыйдәләрне даими үтәү гадәте тәрбияләү.

**Тематика детской литературы рекомендованное читать вслух**

*Родная страна, родной язык, Родина Татарстан, общечеловечность, воспитание, семейная жизнь, любовь к труду и обучению, борьба за национальную свободу в истории нашего народа, дружба народов, человек в мире растений и животных, времена года, приключения, писатели о волшебстве и народное творчество, богатые эмоциям и впечатлениям произведения (рассказы, сказки, песни, стихи, шутки, загадки, пословицы).*

**Кычкырып укырга тәкъдим ителгән балалар әдәбияты тематикасы**

Туган илем, туган телем, Ватаным Татарстан, гомумкешелек, әдәп-әхлагы, гаилә тормышы, уку һәм хезмәт сөю, халкыбызтарихында милли азатлык өчен көрәш сәхифәләре, халыклар дуслыгы, тереклек һәм үсемлекләр дөньясында кеше, ел фасыллары, мажаралар, тылсымнар турында язучылар һәм халык иҗат иткән, хис һәм кичерешләргә бай әсәрләр (хикәя, әкият, җыр, шигырь, мәзәк, табышмак, мәкаль).

**Работа с детской книгой**

*Формирование читательской среды (на каждый урок — одна книга). Заинтересовать детей изданными книгами, научить различать книги по содержанию, правильно назвать книгу, произведения, прочитать имя человека, написавшего книгу (автора). Организация простых игр на уроке по произведению внеурочной книги. Использование литературно-речевых образцов (слова, словосочетания, сказания, пословицы, предложения и т.д.).*

*Соблюдение правил гигиены чтения и хранения книг.*

**Балалар китабы белән эшләү**

Китап уку даирәсен формалаштыру (һәр дәрескә — бер китап). Балалар өчен басылган китаплар белән кызыксындыру, китапларны эчтәлегенә карап аера белергә өйрәтү, китап, әсәр исемнәрен дөрес әйтү, китапны язган кешенең (авторның) исемен укып күрсәтү. Дәрестә, дәрестән тыш укылган китап, әсәр буенча гади генә уеннар оештыру. Сөйләгәндә, әсәрдән алынган әдәби сөйләм үрнәкләреннән файдалану (сүзләр, сүзтезмәләр, әйтемнәр, мәкальләр, җор җөмләләр һ. б.).

Уку гигиенасы һәм китапны саклап тоту кагыйдәләрен утәү.

**Развитие разговорной речи**

*Культура речи. Усиление внимания у детей к голосам своей речи, а также речи других людей; развитие слуховой чувствительности и памяти, движения органов речи. Совершенствовать общие навыки речи, обучать плавному темпу и ритму речи, дыханию и потоку речи, среднему голосу (говорить без напряжения) и правильной интонации (повышать, понижать голос).*

*Последовательное произношение в соответствии с орфоэпическими нормами. Литературно правильное произношение парных звуков на родном языке, особенно дети часто путают, учат правильно произносить звуки з — с, ч — с, н — ң, х — һ, ш — ж, җ — й, п — б, w — в и др.*

*В некоторых диалектах работа над устранением недостатков, выходящих за рамки литературной нормы(туНган, боДау, баргаЛЛар, әйтсәнДӘГЕН, Йомга, СҮли һ. б.).*

*Работа над словом. Выявление, уточнение, обогащение и активизация детского словаря.Правильное (уместное) использование слов, обозначающих предметы, их признаки, действия, время и место действия (вчера, сегодня, утром, завтра утром, в, здесь, впереди, в стороне, вверху, вверху, внутри, снаружи снизу, внизу и т.д.) и разъяснение их смысла. Объединение и разделение предметов по значимым признакам, правильное употребление слов, обозначающих группу и вид (животное, птица, зверь, корова, олень, курица, тетерев и др.). Умение находить нужные слова для точного выражения мысли и вводить их в правильную грамматическую связь (вчера вечером, завтра утром, красивое лицо, стройная фигура, красивый цветок, пишет на доске, решает на доске, начинается на гласный звук, заканчивается на согласный, организует выставку, делает наглядный материал и др.). Развитие чувствительных к смысловым оттенкам слов, распознавание, разделение многозначных, смысловых, противоположных слов на простейших примерах. Учить детей использовать в своей речи слова, фразы, использованные в литературных произведениях в переносном смысле (образно).*

*Использование слов в правильной грамматической форме, очищение речи от неправильных литературных слов.*

**Әйтмә сөйләмне үстерү**

Сөйләмнең аваз культурасы. Балаларда үз сөйләменең, шулай ук башка кешеләр сөйләменең авазларына игътибарны көчәйтү; ишетү сизгерлеген һәм хәтерен, сөйләм органнары хәрәкәтен үстерү. Сөйләмнең гомуми күнекмәләрен камилләштерү, сөйләмнең салмак темпы һәм ритмына, сөйләм сулышына һәм агышына, уртача тавышка (көчәнмичә кычкырып сөйләүгә) һәм дөрес интонациягә (тавышны күтәрә, түбәнәйтә белергә) өйрәтү.

Сүзләрне (аеруча иҗек-аваз төзелеше катлаулы булганнарын) орфоэпия нормаларына туры китереп, басымнарнысаклап әйтүне эзлекле камилләштерә бару. Туган телдәге парлы авазларны әдәби дөрес әйтү, аеруча балалар еш бутый, бозып әйтә торган *з — с, ч — с, н — ң, х — һ, ш — ж, җ* — й, *п — б, w — в* Һ. б. авазларны ишетеп аера, дөрес итеп әйтә белергә өйрәтү (сүзләрдә, җөмләләрдә, тизәйткеч, тел чәбәләндергечләрдә анык итеп әйтү).

Кайбер сөйләшләрдә әдәби нормадан читкә чыккан кимчелекләрне бетерү өстендә эшләү *(туНган, боДау, баргаЛЛар, әйтсәнДӘГЕН, Йомга, СҮли* һ. б.).

Сүз өстендә эшләү. Балаларның сүзлеген (сүзлек хәзинәсен) ачыклау, аныклау, баету һәм активлаштыру. Предметларны, аларның билгеләрен, эш-хәрәкәтләрен белдергән, хәрәкәт вакытын һәм урынын күрсәткән (кичә, бүген, иртә, иртә иртәгә, ары, бире, монда, алда, читтә, өстә, югары, эчтә, тышта түбән, аста һ. б.) сүзләрне дөрес (урынлы) куллану һәм аларның мәгънәләрен аңлату. Мөһим билгеләре буенча предметларны берләштерү һәм аеру, төркемне һәм төрне атаган сүзләрне дөрес куллану *(хайван, кош, җәнлек, сыер, болан, тавык, көртлек* һ. б.). Уйны төгәл белдерү өчен кирәк булган сүзләрне таба һәм аларны дөрес грамматик бәйләнешкә кертә белү *(кичә кич, иртәгә иртән, чибәр йөз, зифа буй, матур гөл, тактага яза, тактада чишә, сузык аваздан башлана, тартык авазга бетә, күргәзмә оештыра, күрсәтмә әсбап ясый* һ. б). Сүзләрнең мәгънә төсмерләренә сизгерлек сыйфатын үстерү күп мәгънәле, мәгънәдәш, капма-каршы мәгънәле сүзләрне иң гади мисалларда тану, аеру. Әдәби әсәрләрдәге күчерелмә мәгънәдә (образлы итеп) кулланылган сүзләрне, әйтелмәләрне балаларның үз сөйләмендә кулланырга өйрәтү.

Сүзләрне грамматик дөрес формада куллану, сөйләмне әдәби дөрес булмаган сүзләрдән арындыру.

**Составление предложений и работа над связной речью**

*Совершенствование речевого мастерства детей дошкольного возраста. Хорошо продумать ответ на вопрос учителя, четко, корректно и коротко. Использование различных типов предложений в ответе.*

*Рассказать знакомую сказку или рассказ по вопросам учителя, не пропуская фрагменты текста, не меняя места.*

*Повествование по рисункам или серии рисунков с небольшими рассказами на общую тему, в которых сохранена комбинированная фраза или сюжетная логика.*

*Устные ответы на поставленные вопросы в отношении прочитанных предложений или текстов.*

*Устное описание различных явлений с помощью учителя. Наполнение сюжета, добавление к началу маленького рассказа, особенно к концу, самостоятельно придумывая различные явления и ситуации.*

*Организация устного повествования детей о событиях своей жизни по аналогии с рассказом или по сюжету, предложенный учителем.*

*Подробное объяснение загадок; выговор стихов, песен, частушек, считалка, скороговорок и шуток, повествование их в разной интонации в той мере, в какой требуется содержание.*

*Развитие грамматической достоверности, точности, полноты, насыщенности детской речи, насыщенности чувствами, впечатлениями, последовательностью, содержательностью и художественностью при устном сочинении и повествовании своих рассказов и содержания прочитанного текста.*

*Воспитание у каждого учащегося внимательного и доброжелательного отношения к ответам и речам других учащихся.*

**Җөмлә төзү һәм бәйләнешле сөйләм өстендә эшләү**

Балаларның мәктәпкәчә яшьтә ирешкән сөйләү осталыгын камилләштерү. Укытучы соравына биреләчәк җавапны яхшылап уйлап җиткерү, анык, төзек һәм кыска гына төгәл итеп әйтү. Җавапта төрле тип җөмләләр куллану.

Текст кисәкләрен төшереп калдырмыйча, урыннарын алыштырмыйча, таныш әкият яки хикәя эчтәлеген укытучы сораулары буенча сөйләү.

Рәсем яки рәсемнәр сериясе буенча гомуми бер темага берләштерелгән җөмләләр яки сюжет логикасы сакланган кечкенә хикәяләр төзеп сөйләү.

Укылган җөмләләргә яки текстларга карата куелган сорауларга телдән җавап бирү.

Әдәби әсәрдәге хәлләргә бәйле сүзләрне кулланып, төрле күренешләрне укытучы ярдәмендә телдән сурәтләү. Сюжетны тулыландыру, кечкенә хикәя башына, аеруча ахырына, мөстәкыйль рәвештә төрле күренеш һәм хәлләр уйлап чыгарып өстәү.

Укыган хикәядәге вакыйгаларга охшашлык буенча яки укытучы тәкъдим иткән сюжет буенча балаларның үз тормышында булган хәлләр турында телдән кечкенә хикәяләр төзеп сөйләүләрен оештыру.

Табышмакларны җентекләп аңлату; шигырь, җыр, такмак, такмаза, санамыш, тизәйткеч һәм мәзәкләрне ятлау, эчтәлек таләп иткән дәрәҗәдә аларны төрле интонациядә сөйләү.

Үз хикәяләрен телдән иншалаганда һәм укыган текст эчтәлеген сөйләгәндә, балалар сөйләменең грамматик дөреслеген, төгәллеген, тулылыгын, хисләргә, кичерешләргә бай, эзлекле, эчтәлекле һәм нәфис булуын үстерү.

Башка укучыларның җавапларына һәм сөйләмнәренә игътибарлы һәм теләктәш мөнәсәбәттә булу сыйфатын һәр укучыда тәрбияләү.

**Послебукварный период**

**Әлифбадан соңгы чор**

**Стихи и проза. Создание общего представления о поэтических произведениях. Название литературного произведения, автор (писатель, поэт), неизвестность в устном народном творчестве (нет автора).**

**Шигырь һәм проза.** Шигъри һәм чәчмә әсәрләр турында гомуми күзаллау булдыру. Әдәби әсәрнең исеме, авторы (язучы, шагыйрь), халык авыз иҗатында билгесезлек (авторы юк).

***Народное устное творчество и литература.*** *Создание общего представления о народном устном творчестве. Отсутствие автора, устная речь, небольшие жанровые произведения практического игрового характера. Колыбельные песни, считалки, загадки, скороговорки, обращения.Практическое освоение таких форм устного народного творчества, как загадка, оборотная сказка.*

**Халык авыз иҗаты һәм әдәбият.** Халык авыз иҗаты турында гомуми күзаллау булдыру. Авторның булмавы, телдән сөйләм, практик уен характерындагы кече жанр әсәрләре. Бишек җырлары, санамыш, табышмак, тизәйткеч, эндәшләр. Халык авыз иҗатының табышмак, әйләнмәле әкият кебек формаларын практик яктан үзләштерү.

Авторская мысль к описываемым событиям (название произведения, характеристика героев, авторская оценка).

Сурәтләнгән вакыйгаларга карата автор фикере (әсәр исеме, геройларга характеристика, авторлар бәяләмәсе).

***Эмоциональный тон произведения.*** *Произведения юмористического и серьезного характера. Умение выражать эмоциональный характер при чтении произведений вслух и наизусть. Оттенки голоса: интонация, тон, сила звука, тембр, темп, пауза, логическое давление, словесная мимика, движения, умение правильно передать голос.*

**Әсәрнең эмоциональ тоны.** Юмористик һәм җитди характердагы әсәрләр. Әсәрләрне китаптан кычкырып, яттан укыганда эмоциональ характерны чагылдыра белү. Тавыш төсмерләре: интонация, тон, тавыш көче, тембр, темп, пауза, логик басым, сүзсез мимика, хәрәкәтләр, ымнарны дөрес бирә алу.

***Средства литературного искусства.*** *Умение находить художественные средства при анализе текстов. Формирование первичного представления о изобразительных средствах, понимание смысла повторений, выявление художественной выразительности звука: понятие «рифма», «ритм».*

**Әдәби сәнгатьлелек чаралары.** Текстларны анализлаганда сәнгатьлелек чараларын табарга күнектерү. Сурәтләү чаралары турында беренчел күзаллау булдыру, кабатлауларның мәгънәсенә төшенү, тавышның сәнгатьлелеген ачыклау: «рифма», «ритм» төшенчәсе бирү.

***Литературные жанры.*** *Создание общего представления о жанрах.*

**Әдәби жанрлар.** Жанрлар турында гомуми күзаллау булдыру.

***Рассказ.*** *Название рассказа. Умение сравнивать два образа, высказывать свое мнение по отношению к героям произведения.*

**Хикәя.** Хикәянең исеме. Ике образны чагыштырып сөйли белү, әсәрдәге геройларга карата үз фикерен белдерү.

***Стихотворение.*** *Познать мир глазами поэтов: убедить поэтов в том, что они учат чувствовать красоту. Знакомство с рифмой: его умение находить и использовать навыки.*

**Шигырь.** Дөньяны шагыйрьләр күзлегеннән чыгып танып белү: шагыйрьләрнең матурлыкны тоя белергә өйрәтүләренә инандыру. Рифма белән танышу: аны таба һәм куллана белергә күнектерү.

***Библиографическая культура.*** *Легко ориентироваться в учебнике: быстрый поиск нужного произведения со страницы» содержание".*

**Библиографик культура.** Дәреслектә җиңел генә ориентлашырга өйрәтү: «Эчтәлек» битеннән кирәкле әсәрне тиз генә эзләп табу.

***Учебные навыки.*** *Привычка читать быстро и быстро. При чтении необходимо четко соблюдать нормы орфоэпии, научить читать с правильными звуковыми оттенками (сила звука, темп).*

**Уку күнекмәләре.** Укучыларны тиз һәм йөгерек укырга гадәтләндерү. Укыганда орфоэпия нормаларын төгәл саклау, дөрес тавыш төсмерләре (тавыш көче, темпы) белән укырга өйрәтү.

## *Содержание программы 2 класса (34 часа)*

## 2 нче сыйныф программасы эчтәлеге (34 сәг)

### *Устное народное творчество*

***Сказки о животных****. Общее представление о сказках. Сходства и различия главного героя в татарских народных сказках и главного героя в сказках других народов. Характер героев. Сказки народов России.*

***Волшебные сказки.*** *Сравнение земного и волшебного мира. Волшебные предметы, (палка, из которой выходит воин, полный всяких продуктов, мешок с сокровищами, невидимый для человеческого глаза волк, змея, сапоги, меч, который убивает врага и т.д., волшебные вещи, которые использует герой: расческа, зеркало, богиня, кольцо. Волшебные помощники (звери: петух, волк, медведь, заяц, Баба-Яга и др.), волшебные цвета (белый и черный). Отражение древнего мира в волшебных сказках (силы природы, превращение людей в животных, растения).*

*Строительство волшебных сказок (цепочка событий, повторения, определенный ритм, запоминание сказки).*

**Халык авыз иҗаты**

**Хайваннар турында әкиятләр.** Әкиятләр турында гомуми кузаллау. Татар халык әкиятләрендәге төп герой белән башка халыклар әкиятләрендәге төп герой арасындагы охшаш һәм аермалы яклар. Геройларның характеры. Россия халыклары әкиятләре.

**Тылсымлы әкиятләр.** Җирдәге һәм тылсымлы дөньяны чагыштыру. Тылсымлы предметлар, (эченнән гаскәр чыга торган таяк,төрле ашамлыклар тулы тырыс, хәзинәсе бер дә кимеми торган сумка, кеше күзенә күрсәтми торган бүрек, җилән, зур атлата торган итек, дошманны кырып сала торган кылыч һ. б., герой куллана торган тылсымлы әйберләр: тарак, көзге, кайрак, балдак. Тылсымлы булышчылар ( җәнлекләр: этәч, бүре, аю, куян, убырлы карчык, һ.б.), тылсымлы төсләр (ак һәм кара). Борынгы дөньяның тылсымлы әкиятләрдә чагылышы (табигать көчләре, кешеләрнең хайваннарга, үсемлекләргә әверелеше).

Тылсымлы әкиятләрнең төзелеше (вакыйгаларның чылбыр рәвешендә баруы, кабатланулар, билгеле бер ритм, әкиятне истә калдыру).

***Авторские произведения***

*Волшебные сказки, написанные в поэтической форме (“Сказка о козе и овце” Г. Тукая), его сходство с народными сказками, особенности сюжета и композиции. Две противоположные мирские победы (земные и волшебные, волшебные помощники, волшебные вещи, волшебные цвета). Неповторимая красота авторского языка. Сходство с народным устным творчеством (повторения, единство событий и др.))*

**Автор әсәрләре**

Шигъри формада язылган тылсымлы әкиятләр (Г. Тукай “Кәҗә белән сарык әкияте”), аның халык әкиятләре белән охшашлыгы, сюжет һәм композиция үзенчәлеге. Капма-каршы ике төрле дөнья бирелеше ( җирдәге һәм тылсымлы, тылсымлы булышчылар, тылсымлы әйберләр, тылсымлы төсләр). Автор теленең кабатланмас матурлыгы. Халык авыз иҗаты белән охшашлык (кабатланулар, вакыйгалар бергәлеге һ.б.)

***Жанр рассказа.*** *(А. Ахмет, Г. Ибрагимов, И. Туктар, Л. Лерон,А. Моталлапов, Э. Шарифуллина).*

*Особенности жанра: жизнерадостность описываемых событий; актуальность нравственных проблем; вымыслы. Главный смысл рассказа. Содержание названия рассказа. Отражение героев рассказа, их портретов и характеров через повествование, выполненные действия. Отношение автора к своему герою.*

**Хикәя жанры.** ( А. Әхмәт, Г. Ибраһимов, И. Туктар, Л.Лерон,Ә Моталлапов, Э. Шәрифуллина).

Жанр үзенчәлекләре: сурәтләнгән вакыйгаларның тормышчанлыгы; әхлакый проблемаларның актуальлеге; уйдырмалар. Хикәянең төп мәгънәсе. Хикәя исеменең эчтәлеккә туры килүе. Хикәя геройлары, аларның портретлары һәм характерларының сөйләмнәре, башкарган гамәлләре аша чагылышы. Авторның үз героена мөнәсәбәте.

***Поэзия***

*Единство человека и природы. Представление мира глазами поэта. Красота окружающего мира-залог вдохновения для поэта. В стихах сравнение, охлаждение, эпитет. Сходство в произведениях автора и народном устном творчестве .Умение находить простые литературные приемы, такие как сравнение, контраст, оживление. Упражнение на усвоение важных средств живой речи: темп,сила голоса.. тон, речевая мелодика (повышение, понижение голоса).*

**Шигърият**

Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып кузаллау. Әйләнә-тирә дөньяның матурлыгы — шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуга инандыру. Шигырьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет. Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык .Чагыштыру, контраст,, җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп,тавыш көче.. тон, сөйләм мелодикасы (тавышны күтәрү, түбәнәйтү)

***Формирование библиографической культуры***

*Знакомство с ” содержанием", поиск нужного ему произведения, организация внеурочной деятельности младшего школьного ребенка: использование домашних, школьных библиотек. Словарь по науке, справочная литература, работа с периодическими изданиями.Работа с детской книгой. Основные элементы книги: обложка, книжная загадка, страницы. Создание навыков хранения книг.*

**Библиографик культура формалаштыру**

“Эчтәлек ” белән танышу , аңа карап, кирәкле әсәрне китаптан таба белү, кече яшьтәге мәктәп баласының дәреслектән тыш эшчәнлеген оештыру: өй, мәктәп китапханәләреннән файдалану. Фән буенча сүзлек, белешмә әдәбият, вакытлы матбугат белән эшләү.Балалар китабы белән эшләү. Китапның төп төп элементларын аеру: китап тышлыгы, китап төпсәсе, битләре. Китапны саклап тоту күнекмәләре булдыру.

***Формирование навыков чтения, речи, прослушивания***

*Формирование навыков художественного чтения (интонация, тон, темп, чтение вслух) представление картины, которую Автор хочет передать. Умение учиться изнутри. Обучаясь в форме цепочки, зная свое место, учиться по очереди.Выполнять анализ прочитанного произведения.*

**Уку, сөйләү, тыңлау күнекмәләре формалаштыру**

Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштыру (интонация, тон, темп саклап кычкырып уку) Автор бирергә теләгән картинаны күзаллау. Эчтән укый белергә күнектерү. Чылбыр рәвешендә укыганда үз урыныңны белеп , чират буенча уку.Укылган әсәргә анализ ясау.

***Содержание программы 3 класса (34 часа)***

**3 нче сыйныф программасы эчтәлеге (34 сәг)**

***Сказки о животных***

*Создание общего представления о животных, являющихся одним из видов устного народного творчества и живущих во всех национальностях земли, передаваемых из поколения в поколение. Вековой рост сказок. Простая лента времени: 1) очень древние сказки, 2) древние, 3) объяснение не очень древних сказочных событий.*

*В очень древних сказках основное место занимают взаимоотношения животных, их внешность. В старинных сказках воспевается мастерство героя, его хитрость. А сказочные события ставят перед собой цель показать добрые дела героя, его способности, великодушие. Создается представление о ходячих сказках.*

**Хайваннар турында әкиятләр**

Халык авыз иҗатының бер төре булган һәм җир йөзендәге барлык милләтләрдә дә яшәп килүче, буыннан буыннарга күчеп йөрүче хайваннар турындагы әкиятләр турында гомуми кузаллау булдыру. Әкиятләрнең гасырлар дәвамында үсеше. Гади вакыт тасмасы: 1) бик борынгы әкиятләр, 2) борынгы, 3) бик борынгы булмаган әкияти вакыйгалар турында аңлату.

Бик борынгы әкиятләрдә хайваннар арасындагы мөнәсәбәтләр, аларның тышкы күренешләре төп урынны алып тора. Борынгы әкиятләрдә геройның аңы, хәйләгә осталыгына дан җырлана. Ә әкияти вакыйгалар исә үз эченә геройның изге эшләрен, аның сәләтен, киң күңеллеген күрсәтүне максат итеп куя. Йөремсәк әкиятләр турында кузаллау булдырыла.

**_Басни жанра_**

*Толкование басен состоит из двух частей: повествования (исторического события) и морального (итога, воспитательного объяснения). Акцентировать внимание на сказочном происхождении повествовательной части басни. Сходство моральной части басен с пословицами. Происхождение, развитие жанра масала. Изучение всемирно известных басен Эзопа, Ж. Лафонтена, И. Крылова, татарских мыслителей К. Насыри, Г. Тукая, М. Гафури, Т. Яхина, Г. Шамукова, А. Исхака, Ф. Яхина и др.*

**Мәсәлләр жанры**

Мәсәлләрнең ике өлештән: хикәяләү (тарихи вакыйга) һәм мораль (нәтиҗә, тәрбияви аңлатулар) торуын аңлату. Мәсәлнең хикәяләү өлешенең әкиятләрдән килеп чыгуына басым ясау. Мәсәлләрнең мораль өлешенең мәкальләр белән охшашлыгы. Мәсәл жанрының килеп чыгышы, үсеше. Бөтендөньяга танылган мәсәлчеләр: Эзоп, Ж. Лафонтен, И. Крылов, татар мәсәлчеләре К. Насыйри, Г. Тукай, М. Гафури, Т. Яхин, Г. Шамуков, Ә. Исхак, Ф. Яхин һәм башкалар турында өйрәнү.

**_Пословицы_**

*Пословицы-это древнее слово, пословицы, пословицы, пословицы, плоды опыта и мудрости, сокровища, которые должны храниться в памяти, коллективное мнение народа, правила жизни, доказательства слова, советы в жизни. Слово пословица заимствовано из арабского языка, означающее “слово, произнесенное на якитском месте”. Пословицы разных народов. Использование пословиц в речи, в баснях уместно.*

**Мәкаль жанры**

Мәкальләр – ул борынгылар сүзе, аталар сүзе, картлар сүзе, тәҗрибә һәм хикмәт җимеше, хәтердә сакланырга тиешле хәзинә, халыкның күмәк фикере, тормыш кагыйдәсе, сүзгә дәлил, тормышта киңәш. Мәкаль сүзе гарәп теленнән алынган, “урынлы сүз якитиешле урында әйтелгән сүз” дигән мәгънәне аңлатуын төшендерү. Төрле халыклар мәкальләре. Мәкальләрне сөйләмдә, мәсәлләрдә урынлы куллану.

**_Формирование представления о жанре рассказа_**

*Герои рассказа, их портреты и особенности характера, их действия. Отношение автора к своему герою. Сравнительная характеристика героев. Среда обитания героя, пейзаж.*

**Хикәя жанры турында кузаллау формалаштыру**

Хикәя геройлары, аларның портретлары һәм характер үзенчәлекләре, башкарган гамәлләре аша чагылышы. Авторның үз героена мөнәсәбәте. Геройларга чагыштырма характеристика. Герой яшәгән тирәлек, пейзаж.

**_Формирование представления о самобытности жанра сказки и рассказа._**

*Объяснение композиционной самобытности жанров сказки и рассказа (через наблюдения). Показать читателю-слушателю тайну природных сил, таинственное течение жизни сказочных героев, охарактеризовать героев рассказа, отражая события из жизни.*

**Әкият һәм хикәя жанрының үзгәлеге турында кузаллау формалаштыру**

Әкият һәм хикәя жанрларының композиция үзенчәлеген (күзәтүләр аша) аңлату. Укучы-тыңлаучыга табигый көчләрнең серен, әкият геройларының серле тормыш агышын күрсәтү, хикәя геройларының характерын тормыштан алынган вакыйгаларны чагылдырып сөйләү.

***Поэзия***

*Единство человека и природы. Представление мира глазами поэта. Красота окружающего мира-залог вдохновения для поэта. В стихах сравнение, охлаждение, эпитет. Сходство в произведениях автора и народном устном творчестве. Умение находить простые литературные приемы, такие как сравнение, контраст, оживление. Упражнения по овладению важными средствами живой речи: темп, сила голоса, тон, речевая мелодика (повышение, снижение голоса).*

**Шигърият**

Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып кузаллау. Әйләнә-тирә дөньяның матурлыгы — шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуга инандыру. Шигырьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет. Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык. Чагыштыру, контраст, җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп, тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы (*тавышны күтәрү, түбәнәйтү*).

***Время ленты.*** *Показ сказок из фольклорных произведений на ленте времени(очень древние, древние, сказочные события)*

**Вакыт тасмасы**

Фольклор әсәрләреннән әкиятләрне вакыт тасмасында күрсәтү(*бик борынгы, борынгы, әкияти вакыйгалар*)

***Формирование библиографической культуры.***

*Знакомство с " содержанием", поиск нужного ему произведения, организация внеурочной деятельности младшего школьного ребенка: использование домашних, школьных библиотек. Словарь по науке, справочная литература, работа с периодическими изданиями. Работа с детской книгой. Основные элементы книги: обложка, книжная загадка, страницы. Создание навыков хранения книг. Изучение составления различных сборников.*

**Библиографик культура формалаштыру**

“Эчтәлек ” белән танышу , аңа карап, кирәкле әсәрне китаптан таба белү, кече яшьтәге мәктәп баласының дәреслектән тыш эшчәнлеген оештыру: өй, мәктәп китапханәләреннән файдалану. Фән буенча сүзлек, белешмә әдәбият, вакытлы матбугат белән эшләү. Балалар китабы белән эшләү. Китапның төп элементларын аеру: китап тышлыгы, китап төпсәсе, битләре. Китапны саклап тоту күнекмәләре булдыру. Төрле җыентыклар төзергә өйрәнү.

***Формирование навыков чтения, речи, прослушивания***

*Формирование навыков художественного чтения (интонация, тон, темп, чтение вслух) представление картины, которую Автор хочет передать. Умение учиться изнутри. Обучаясь в форме цепочки, зная свое место, учиться по очереди.Выполнять анализ прочитанного произведения Развитие учебной техники*

**Уку, сөйләү, тыңлау күнекмәләре формалаштыру**

Сәнгатьле уку күнекмәләре формалаштыру (интонация, тон, темп саклап кычкырып уку) Автор бирергә теләгән картинаны күзаллау. Эчтән укый белергә күнектерү. Чылбыр рәвешендә укыганда үз урыныңны белеп , чират буенча уку.Укылган әсәргә анализ ясау. Уку техникасын үстерү

***Содержание программы 4 класса (34 часа)***

**4 нче сыйныф программасы эчтәлеге (34 сәг)**

***Устное народное творчество.***

**Халык авыз иҗаты**

***Создание общего представления о мифах***

*Жизнь древних народов, взаимоотношения человека и природы. Дерево жизни, тотемные животные и тотемные растения, люди к ним относятся, сохранение древних традиций.*

**Мифлар турында гомуми кузаллау булдыру**

Борынгы халыкларның тормышы, кеше һәм табигать арасындагы мөнәсәбәт. Тормыш агачы, тотем хайваннар һәм тотем үсемлекләр, кешеләрнең аларга карашы, борынгы традицияләрнең сакланышы.

***Волшебные сказки***

*Отражение древних представлений о мире. Волшебный сказочный герой. Волшебный мир, волшебные предметы, волшебные цифры, слова, волшебные помощники. Законы волшебной сказки: герой сказки уходит из игры, путь к достижению цели (мир магии, путь через дремучие леса, испытания, волшебная помощь, радость победы). Отражение народных сказок в мифах, легендах. Легенды и легенды. Герои сказок и легенд, их переживания. Исторический контакт. Разные термины, их происхождение. В сказках отражены события, сказанные в легендах и легендах.*

**Тылсымлы әкиятләр**

Дөнья турында борынгы кузаллаулар чагылышы. Тылсымлы әкият герое. Тылсым дөньясы, тылсымлы предметлар, сихри саннар, сүзләр, тылсымлы булышчылар. Тылсымлы әкият законнары: әкият герое өеннән чыгып китә, максатка ирешү юлы (тылсым дөньясы, карурманнар аша үтүче юл, сынаулар, тылсымлы булышчы ярдәме, җиңү шатлыгы). Халыклар әкиятләренең мифлар, легендаларда чагылышы.

***Легенды***

*Герои сказок и легенд, их переживания. Исторический контакт. Разные термины, их происхождение. В сказках отражены события, сказанные в легендах и легендах.*

***Риваять һәм легендалар***

Риваять һәм легендаларда сөйләнгән геройлятьар, аларның кичерешләре. Тарихи бәйләнеш. Төрле атамалар, аларның килеп чыгышы. Риваять һәм легендаларда бирелгзн вакыйгаларның әкиятләрдә чагылышы.

***Авторские сказки***

*Сходство авторских сказок с народными сказками. (жанр и сюжет). Волшебные победы в народных сказках, в авторских сказках*

**Автор әкиятләре**

Автор әкиятләренеңхалык әкиятләре белән охшашлыгы. (жанр һәм сюжет). Халык әкиятләрендәге тылсым белән җиңүләр, автор әкиятләрендә акыл белән эш итеп уңышка ирешү, ярату һәм яратыла белүнең көче.

***Фольклорный жанр в жизни, в настоящее время***

*Народные традиции и праздники. Гимны (гимн Татарстана). Народные и авторские сказки.*

**Фольклор жанрының тормышта, хәзерге вакытта яшәеше**

Халык традицияләре һәм бәйрәмнәре. Гимннар (Татарстан гимны). Халык һәм автор әкиятләре.

***Рассказ***

*Продолжение формирования представления о жанре рассказа. Герои рассказа, их портреты и особенности характера, их действия. Отношение автора к своему герою. Сравнительная характеристика героев. Сложность характера героя, связь со временем. Среда обитания героя, пейзаж. Отражение действительности в рассказе. Единицы литературного языка.*

**Хикәя**

Хикәя жанры турында кузаллау формалаштыруны дәвам итү**.** Хикәя геройлары, аларның портретлары һәм характер үзенчәлекләре, башкарган гамәлләре аша чагылышы. Авторның үз героена мөнәсәбәте. Геройларга чагыштырма характеристика. Герой характерының катлаулылыгы, вакыт белән бәйләнеше. Герой яшәгән тирәлек, пейзаж. Хикәядәге чынбарлык чагылышы. Әдәби тел берәмлекләре.

***Формирование представления о самобытности жанра сказки и рассказа***

*Объяснение композиционной самобытности жанров сказки и рассказа (через наблюдения). Показать читателю-слушателю тайну природных сил, таинственное течение жизни сказочных героев, охарактеризовать героев рассказа, отражая события из жизни.*

**Әкият һәм хикәя жанрының үзгәлеге турында кузаллау формалаштыру**

Әкият һәм хикәя жанрларының композиция үзенчәлеген (күзәтүләр аша) аңлату. Укучы-тыңлаучыга табигый көчләрнең серен, әкият геройларының серле тормыш агышын күрсәтү, хикәя геройларының характерын тормыштан алынган вакыйгаларны чагылдырып сөйләү.

***Поэзия***

*Единство человека и природы. Представление мира глазами поэта. Красота окружающего мира-залог вдохновения для поэта. В стихах сравнение, охлаждение, эпитет. Сходство в произведениях автора и народном устном творчестве. Умение находить простые литературные приемы, такие как сравнение, контраст, оживление. Упражнения по овладению важными средствами живой речи: темп, сила голоса, тон, речевая мелодика (повышение, снижение голоса).*

**Шигърият**

Кеше һәм табигать бергәлеге. Дөньяны шагыйрь күзлегеннән чыгып кузаллау. Әйләнә-тирә дөньяның матурлыгы — шагыйрь өчен илһам чишмәсе булуга инандыру. Шигырьдә чагыштыру, сынландыру, эпитет. Автор әсәрләрендә һәм халык авыз иҗатында охшашлык.

Чагыштыру, контраст, җанландыру кебек гади әдәби алымнарны таба белү. Җанлы сөйләмнең мөһим чараларын үзләштерү күнегүләре: темп, тавыш көче, тон, сөйләм мелодикасы (тавышны күтәрү, түбәнәйтү).

***Об авторах произведения***

*Биография поэта, писателя, художников.*
*а) авторские впечатления;*
*б) отражение авторских наблюдений;*
*в) встречи с современными авторами, вопросы детей к автору, ответы.*

**Әсәр авторлары турында**

Шагыйрь, язучы, рәссамнарның биографиясе.
а) әсәрдә авторлар кичереше;
ә) автор күзәтүләренең чагылышы;
б) хәзерге заман авторлары белән очрашу, балаларның авторга сораулары, җаваплар.

***Формирование библиографической культуры***

*Знакомство с ” содержанием", поиск нужного ему произведения, организация внеурочной деятельности младшего школьного ребенка: использование домашних, школьных библиотек. Словарь по науке, справочная литература, работа с периодическими изданиями. Работа с детской книгой. Основные элементы книги: обложка, книжная загадка, страницы. Создание навыков хранения книг. Изучение составления различных сборников. Сбор информации об авторах произведения. Формирование навыков чтения, речи, прослушивания Формирование навыков художественного чтения (интонация, тон, темп, чтение вслух) представление картины, которую Автор хочет передать. Умение учиться изнутри. Обучаясь в форме цепочки, зная свое место, учиться по очереди. Выполнять анализ прочитанного произведения Развитие учебной техники.*

**Библиографик культура формалаштыру**

